Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге

Питрәч авыл җирлеге башлыгы
карары

31 октябрь, 2022 ел №9

Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 18 августындагы 65 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегендә (2017 елның 15 декабрендәге 79 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 92 номерлы, 2019 елның 08 октябрендәге 137 номерлы үзгәрешләре белән) иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, кергән гаризаны карап карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч авылы, Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан 637 кв.м мәйданлы, кадастр номеры 16:33:120131:16 булган җир участогында рөхсәт ителгән иң чик параметрлардан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне бидгеләргә:

2.1. җәмәгать фикер алышуларын оештыручы – Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия (алга таба - Комиссия);

2.2. җәмәгать фикер алышуларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны – 2022 елның 10 ноябре, 10.00 сәг. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында: 422770, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет урамы, 18 й. адресы буенча;

2.3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең башкарма комитеты - 422770, ТР, Питрәч районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч авылы, Совет урамы, 18 йорт адресы буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итә ала (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 дән 16-00 гә кадәр, төшке тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.);

2.4. Питрәч авыл җирлегенә халыкка җиткерү максатыннан, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет урамы, 18 нче йорт адресы буенча проектның Питрәч авылы башкарма комитеты бинасында күргәзмә-экспозициясен оештырырга (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 дән 16-00 гә кадәр, төшке аш тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Комиссиягә:

3.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру йомгаклары буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә;

3.2. 2022 елның 17 сентябренә кадәр «Вперед» («Алга») район газетасында һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы                                   И.М. Кашапов